ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» 193-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» 193-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 667-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясындагы сигезенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); № 74 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 33 (I өлеш); № 56 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), «указларында» сүзеннән соң «йә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының $138^6$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 26 июнендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды бюджетына субвенцияләр бирү мөмкинлеге карала. Әлеге субвенцияләр Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды идарәсе органына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган гражданнарга социаль ярдәмнең (ярдәм күрсәтүнең) аерым чараларын күрсәтү буенча Россия Федерациясенең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә. Әлеге субвенцияләрне бирү максатлары һәм шартлары Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды идарәсе органы һәм Россия Федерациясе субъектының югары башкарма органы арасындагы килешүләр белән билгеләнәчәк.

Күрсәтелгән Федераль закон 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк.

Шуңа бәйле рәвештә закон проектында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясындагы сигезенче абзацына Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фонды бюджетына субвенцияләр бирү очракларын арттыруны күздә тота торган үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 43 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми һәм Татарстан Республикасы бюджетына керемнәрне алып бетермәүгә китерми.